**Нурмөхәммәтова Р.С.,**

**Казан**

# Р.Харис иҗатында матди мәдәният элементлары

Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап тел белемендә тел һәм мәдәният нисбәтен ачыклауга игътибар артты. Шуңа бәйле рәвештә, лингвистика һәм культурология фәннәре чигендә яңа бер фән – лингвокультурология барлыкка килде. Лингвокультурологик үзенчәлеккә ия булган тел берәмлекләрен ачыклау һәм төрле яклап тасвирлау әлеге фәннең мөһим бурычларыннан санала, чөнки телдәге нәкъ менә шундый берәмлекләр халыкның фикерләү рәвешен чагылдыра һәм формалаштыра.

Теләсә кайсы халыкның мәдәнияте матди һәм рухи элементлардан гыйбарәт. Аларның һәркайсын кеше барлыкка китергәнлектән, лингвокультурологик тикшеренүләрнең үзәгендә *кеше* тора, бу концептны ачыкламый торып, халык мәдәниятен адекват итеп сурәтләү мөмкин түгел. Ни дисәң дә, мәдәни кыйммәтләр системасында теге яки бу әйбернең урыны аның кеше тормышында уйнаган роле белән билгеләнә [Замалетдинов 2009: 126].

Матди дөнья предметларын белдергән лексик берәмлекләр лингвокультурология өчен дә, тел теориясе өчен дә кызыклы объект тәшкил итә. Алар кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, көнкүреш үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләр һәм традицияләрне чагылдыра. Әлеге сүзләр арасында “торак” тематик төркеменә караганнары халыкның иң мөһим матди мәдәният элементларын атый.

*Өй* – барлык кешеләр өчен үзен чолгап алган тирәлектә ориентлашу ноктасы. Ул бары тик кешенеке, аның икенче “мин”е, үз өе булмаган кеше җәмгыятьтә үзен кимсетелгән саный. Бары тик өй генә кешене әйләнә-тирә тәэсиреннән саклый, ул аның дөньядагы шәхси территориясе, кешегә ул бик якын һәм ул аннан аерып карала алмый. Шуңа да өйгә хас булган әлеге үзенчәлекләр халык иҗатының буеннан буена сузылып бара: *өй* салмыйча мал булмый; үз *өе*ң үзеңә ирек; хуҗасыз *өй* таркалыр; *өй* корган уңар, *өй*сез кеше туңар һ.б.

*Өй* сүзе гомумтөрки телдә *үй, эв*, иске татар телендә *өйү*, борынгы төрки телдә *эйү* формаларында кулланылган. Бу сүзне *өй-ү* фигыле белән чагыштыралар. Шулай ук борынгы кытай телендәге иң “квадрат, башня” сүзе нигезендә ясалган” дигән фикер бар [Әхмәтьянов 2001: 158].

*Өй* лексемасы шагыйрьләр иҗатында да төп урынны алып тора. Бу нисбәттән Р.Харис иҗаты да искәрмә түгел. Р.Харис шигырьләрендә *өй*:

- кешенең дөньяга килгән урыны:

Монда (өйдә – Р.Н.) тамган кендек каным,

Һәм шушы *өй*нең һавасы,

Күкрәгемне ертып кереп,

Кычкырткан тәүге авазны. (“Туган йорт капкасы”)

- кешенең, аның гаиләсенең яшәү, тору урыны:

Син юк *өй*гә кайтасым да килми минем. (***)

Безнең *өй*, мин беләм,

Һич җәннәт түгелдер... (“Сәрләүхәсез”) һ.б.

Бу мәгънәсендә *өй*не “йорт”, “фатир”, “коттедж” кебек сүзләр дә алыштырып килергә мөмкин:

Бик иске өйгә дә,

өр-яңа *йорт*ка да

кагарга тиешле

ел саен ун кадак. (“Ун кадак”)

Евро*фатир* чоланында

әбиләрдән калган сандык... (“Сандык”)

Алып йоклый кырда, департаментларда,

мәктәпләрдә, фиркаләрдә, *коттедж*ларда...( “Алып йоклый...”) һ.б.

“Өй” концептының структурасы шактый катлаулы. Ябык пространство буларак, аны тышкы дөнья белән тоташкан чигендә *ишек, тәрәзә, бусага, түбә* кебек өлешләре бар.

Кеше яшәешенең мөһим шарты – тышкы дөнья белән элемтә, димәк, өйнең чыгу-керү өчен уемы булырга тиеш. Ишек һәм тәрәзә өйнең нәкъ шундый

элементларын тәшкил итә, тик бу функцияне алар ачык торганда гына башкара ала [Зиангирова 2007: 82].

Хәзерге татар телендәге “ишек” сүзе гомумтөрки *эшик, әшик* “ишек, капкач, ябу, чыпта, җәймә” – борынгы төрки телдә әл-ик “ябу (щит)” сүзеннән (әл- тамырыннан ясалган) [Әхмәтьянов 2001: 80].

*Ишек* – бина, бүлмә яки корылманың стенасына кереп-чыгып йөрер өчен ясалган уем һәм шул уемга беркетелгән ачылмалы-ябылмалы җайланма (капкач, каплавыч) [ТТАС 2005: 202]. Р.Харис та бу сүзне иң элек шушы мәгънәсендә куллана:

Көн саен йөз тапкыр
ачылган *ишек* тә
бераздан әйләнә
тупсалы тишеккә. (“Ун кадак”)

Синсез өйгә кайтасым да килми минем. <...>
*Ишеге* ят... Ачу газап... Ачтың исә,
өскә ава таштай авыр салкын тынлык. (***)

Мин күнеккән: *ишек* ачсам – синең күзләр. (***)

Кайчак төнлә килеп *ишег*емне
үкенечләр килеп шакыйлар... (“Атмый калган сүз”)

Мин чыгарга диеп ачкан *ишек*тән
кемне керттең? (***)

Үз-үземә төгәл сыям.
Бозмыйм күрше чикләрен.
Ачык *ишек*ләргә керәм... (“Үзем турында”) һ.б.

*Ишек* Р.Харис иҗатында башка йомык пространствога да, мәсәлән, йөрәккә үтеп керү юлы буларак та сурәтләнә. Шагыйрь бу образны бик яратып куллана:

Һәр халыкның һәр *кешесе йөрәгенең*
*ишекләре*н Заман булып кага-кага. (“Алып йоклый...”)

Аның сулу кысылуы,
бәлки, мине күргәчтер,

*йөрәк ишеге*мне ачып,

шигыремә кергәчтер?! (“Сыгылмалы сылу”)

*Йөрәгемнең ишекләре*н шакыдылар... (***) һ.б.

“Кеше күңеле карурман”, “кеше күңеле – караңгы төн”, ди татар халкы, шуның белән ул кешенең эчке, рухи дөньясына, аның хис-тойгыларына үтеп керүнең авырлыгына ишарә итә. Димәк, анда керү өчен дә ачык юл – ишек булу зарур.

*Күңел ишекләре*м тоткасыз.

Ләкин биксез.

Хәтта келәсез. (***)

... юлым уңмас дигән кара шөбһә

*күңел ишеге*ңә какмасын! (***) һ.б.

Татар кешесенең фикерләвендә *ишек*кә *тәрәзә* каршы куела. Ишек ачыла, ябыла, ябык вакытта аннан хәтта яктылык та, җил дә керә алмый, ә тәрәзә тышкы дөнья белән, һичьюгы визуаль рәвештә генә булса да, һәрвакыт элемтәдә торырга ярдәм итә, чөнки ул өйнең, корылманың стенасындагы “яктылык керсен өчен пыяла куелган ачыклык, уем” [ТТАС 2005: 584]. *Тәрәзә* – фарсы-таҗик теленнән *дәричә* “кечкенә ишек, тәрәзә” (*дәр, дар* “ишек”) сүзеннән [Әхмәтьянов 2001: 197].

*Тәрәзә* – өйнең күзе. Тәрәзәсе булган өй ябык пространство булудан туктый, ул тышкы дөньяга ачыла. Тәрәзә ике функция үти: ул кешене йә тышкы дөнья белән тоташтыра (ачыла ала, үтәкүренмәле), яки аңа тоткарлык ясый (чөнки арада пыяла бар).

Р.Хариста *тәрәзә* сүзе “тәрәз” вариантында да очрый (бу сүз гомумән поэзия теленә хас). Шагыйрь әсәрләрендә *тәрәзә/тәрәз*:

- өйне (өй эчендәгеләрне) тышкы дөнья белән бәйли:

Ак дөньяга чыктым *тәрәз* аша

бүген иртә торып карагач... (“Никахлы төс”)

*Тәрәзә*дән кулны сузып,

тартып алдым бер болыт... (***)

Җил кертергә диеп *тәрәз* ачтым... (***)

*Тәрәзә*ңә карадың да,

көн аяза, якты, дидең... (***)

Текәлеп *тәрәзә*гә,

түшәгемнән сикереп тордым... (“Бәсле ботаклар”)

*Тәрәзә*мдә һәр кич кояш байый... (“Кызыл шәфәкъ”) һ.б.

- Тышкы дөньяны өй (өйнең эчендәгеләр) белән бәйли:

*Тәрәзә*ңә көне буе

болыт булып тордым карап... (***)

...шәүлә булып *тәрәзә*ңнең

пыяласын ничә сөрттем... (***)

Яз *тәрәз*дән керә алмый,

керә алмый *ишек*тән дә... (***) һ.б.

- Ачыклыгы, үтәкүренмәлелеге, серлелеге белән чит-ятны әлеге ябык пространствога тартып тора:

Бәсле *тәрәзә*нең җәннәт сыман

гүзәл багларына карап... (“Зәвык бүлмәсе”)

Казан *тәрәз*ләре бизәкле. <...>

Казан *тәрәз*ләре гөл-чәчәк.

Бу *тәрәз*гә кемдер киләчәк. (“Көмеш тотка”)

Һәр вагонның *тәрәзә*се

сөйләп калдыра кыйсса. (“Поездлар үтә тора”) һ.б.

- Якты яки караңгы була (өйдә кеше булу-булмауга бәйле):

Синсез өйгә кайтасым да килми минем.

*Тәрәзә*се саран күзе төсле тонык. (***)

Синең утсыз *тәрәзә*ңнән

күз ала алмый йөрим... (***)

Өйнең *тәрәзә*ләре утсыз...

Бер дә эз юк капкасына. (“Туган йорт капкасы”) һ.б.

- Вакыт үтү белән үзгәрә:

*Тәрәз*ләр кыйшая... (“Ун кадак”)

Шул рәвешчә, татар матди мәдәниятенең бер чагылышы булган “өй” сегментына караган өй, ишек, тәрәзә берәмлекләрен күзәтеп чыгу нәтиҗәсендә аларның Р.Харис иҗатында зур урын алып торуы ачыкланды. Карап үтелгән мисаллар шагыйрь иҗатында алар үзенчәлекле дә, шул ук вакытта традицион мәгънәләрдә дә бирелә. Чыннан да, “өй” һәм аңа бәйле күренешләрне белдергән лексемаларда аерым халыкка хас мәдәни әһәмиятле мәгълүмат туплана. Телне тирән тоемлаган Р.Харис әлеге мәгълүматны түкми-чәчми әсәрләренең үзәгенә салган.

Әдәбият

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г.Әхмәтьянов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2001. – 272 б.

Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии / Р.Р.Замалетдинов. – Казань: Магариф, 2009. – 351 с.

Зиангирова Э.М. Татарская лингвокультурология: функционирование концептов «өй» и «йорт» (на материале произведений М.Магдеева) / Э.М.Зиангирова. – Казань: Казанский гос.унив-т им. В.И.Ульянова-Ленина, 2007. – 217 с.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

Чыганак

Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. 3 т.: Шигырьләр (1995-2005) / Ренат Харис; Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Хәсәнова. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2006. – 511 б.